**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 02.04.2020** **№ 338**

# Урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтү Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

РФ Хөкүмәтенең 2019 нчы елның 29 нчы ноябрендәге 1535 нче номерлы «Урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында Нигезләмәсенә үзгәрешләр кертү турында» Карары нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 нчы елның 7 нче октябрендәге 1707 нче номерлы карары белән расланган урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәтен күрсәтү Административ регламентына 2.5 пунктының 5 пунктчасында «проект-эзләнү» сүзен «махсуслаштырылган» сүзе белән алыштырып үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.Ф. Хәкимуллинга йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин